РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
МОКРОСАВАЛЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӨКЕРЛЕ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.10. 2025 №1-2

Карарның үз көчен югалтуын
тану турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль вазыйфаны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мөкрле авыл җирлеге советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкрле авыл җирлеге Советының 2016 елның 21 апрелендәге 12-1 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мөкрле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Әлши авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында». карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкрле авыл җирлеге Советының 2022 елның 20 маендагы 44-1 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкрле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкрле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы

йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкрле авыл җирлеге Советының 2022 елның 15 сентябрендәге 53-1 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкрле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкрле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкрле авыл җирлеге Советының 2020 елның 14 сентябрендәге 94-1 номерлы «Муниципаль вазыйфаны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Мөкрле авыл җирлеге башлыгы С.Н. Тюплина